КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 31 март г.Казань № 188

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 июнь, 251 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 432 нче, 2007 ел, 5 февраль, 35 нче, 2008 ел, 29 май, 344 нче, 2010 ел, 29 ноябрь, 961 нче, 2013 ел, 12 март, 157 нче, 2014 ел, 13 февраль, 83 нче, 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче, 2019 ел, 13 март, 181 нче, 2020 ел, 23 ноябрь, 1053 нче, 2021 ел, 3 февраль, 47 нче, 2021 ел, 20 февраль, 92 нче, 2021 ел, 10 май, 322 нче, 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче, 2022 ел, 3 март, 194 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы, 2023 ел, 20 март, 282 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның алтынчы абзацына «, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы) яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы) интерактив форманы тутыру юлы белән» сүзләрен өстәргә;

8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза бирүчегә субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) кабул ителгән карар хакында хәбәр итү субсидия-ташлама билгеләү

турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул ителгән көнне гариза бирүче тарафыннан субсидия-ташлама билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр рәвешендә, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында шәхси кабинет аша) гамәлгә ашырыла.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче, 2009 ел, 6 апрель, 203 нче, 2012 ел, 23 февраль, 153 нче, 2013 ел, 12 март, 157 нче, 2014 ел, 25 август, 611 нче, 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче, 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче, 2016 ел, 22 июнь, 425 нче, 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче, 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче, 2019 ел, 11 март, 168 нче, 2019 ел, 13 март, 181 нче, 2019 ел, 20 декабрь, 1173 нче, 2020 ел, 2 июнь, 461 нче, 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы, 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче, 2021 ел, 20 февраль, 92 нче, 2021 ел, 10 май, 322 нче, 2021 ел, 12 июль, 567 нче, 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче, 2022 ел, 3 март, 194 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы, 2023 ел, 11 июль, 809 нчы, 2023 ел, 16 октябрь, 1313 нче, 2024 ел, 16 май, 326 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктның алтынчы абзацына «, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы) яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы) интерактив форманы тутыру юлы белән» сүзләрен өстәргә;

2.4 пунктның ундүртенче абзацында «телефонга СМС-хәбәр итеп» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында шәхси кабинет аша» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин